**Казанның спорт корылмалары**

**Википедия**

https://tt.wikipedia.org/wiki/%D0%A2%D3%A9%D1%80%D0%BA%D0%B5%D0%BC:%D0%9A%D0%B0%D0%B7%D0%B0%D0%BD%D0%BD%D1%8B%D2%A3_%D1%81%D0%BF%D0%BE%D1%80%D1%82_%D0%BA%D0%BE%D1%80%D1%8B%D0%BB%D0%BC%D0%B0%D0%BB%D0%B0%D1%80%D1%8B

**2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада**

http://kazan2013.com/tat/sportobjects

**2013 елда Казанда XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада үткәрү өчен бик күп спорт һәм спорт өчен булмаган корылмалар кулланылачак.**

Спортчыларның тренировкалары һәм ярышлар 49 спорт корылмасында үтәчәк. Аларның 30 Универсиада өчен махсус төзелгән. Июнь аена 27 корылма сафка басты инде. Спорт өчен булмаган корылмаларга спортчылар һәм делегация житәкчеләре яшәячәк Универсиада авылы, Халыкара мәгълүмат үзәге һәм Уеннарны ачу һәм ябу тантаналары үтәчәк стадион керә.

Картадагы барлык спорт корылмалары

Спорт төрләре буенча спорт корылмалары...

https://metshin.ru/tt/posts/20524

10 ел эчендә Казанда Спорт корылмалары саны 1,5 тапкырга арткан

(Казан шәһәре KZN.RU, 25-нче февраль, Алинә Бережная). "Ак Буре" һәм "Триумф" спорт комплексларында энергосервис контрактлары төзелгән, алар спорт залларында яктыртуны ике тапкыр яхшыртырга гына түгел, ә 4,5 млн сумнан артык акчаны янга калдырырга да мөмкинлек бирәчәк, дип хәбәр итте бүген эшлекле дүшәмбедә Физик культура һәм спорт комитеты рәисе Светлана Вострикова, Казанның спорт инфраструктурасы үсеше турында

сөйләгәндә. Илсур Метшин комитетка 15 мартка кадәр 2019 елга һәм киләсе бишьеллыкка энергия сервислары буенча эш турында хисап төзергә кушты. Спорт инфраструктурасы Казанның барлык районнарында да үсеш ала Соңгы 10 елда Казанда спорт корылмалары саны 1,5 тапкырга артты. Шулай итеп, 6 ел эчендә республика программасы буенча Казанда 253 млн. сумлык 93 спорт мәйданчыгы төзелгән, быел тагын 15 спорт мәйданчыгы барлыкка киләчәк. Бу максатларга республика бюджетыннан 46,2 млн сум акча бүленгән. Узган ел республика программасы буенча 44, 5 млн сумлык 12 мәйданчык төзелде, алар арасында 5 мини-футбол кыры, 3 универсаль волейбол-баскетбол мәйданчыгы, 2 тренажерлы мәйданчык һәм ясалма өслекле хоккей тартмалары бар...

**Татар-информ** https://tatar-inform.tatar/news/sport/03-03-2020/tatarstanda-proektlau-stadiyasend-ge-sport-korylmalary-isemlege-bilgele-5726730

**Татарстанда проектлау стадиясендәге спорт корылмалары исемлеге билгеле**

*Проектлау стадиясендә ун объект исәпләнә.*

(Казан, 3 март, «Татар-информ», Гөлнар Гарифуллина). Татарстанда проектлау стадиясендәге спорт корылмалары исемлеге билгеле. Бу хакта мәгълүмат Татарстан Министрлар Кабинетында брифингта билгеле булды. Хәзерге вакытта проектлау стадиясендә ун объект исәпләнә. Казанда Гаврилов урамында киләчәктә Фигуралы шуу төбәк үзәге төзелергә тиеш. Шул ук урамда Комлыктагы спорт төрләре төбәк үзәген төзү ниятләнә...

**Идел буе спорт һәм туризм академиясе**

https://www.sportacadem.ru/tat/akademia1/news/jvghvgvg830/

**Иел буе академиясенең спорт объектлары: нәтиҗәләр ясыйбыз, киләчәкне планлаштырабыз**

**Идел буе академиясенең спорт объектлары: нәтиҗәләр ясыйбыз, киләчәкне планлаштырабыз** Идел буе спорт һәм туризм академиясендә вузның ректоры Якубов Йосып катнашында спорт бинaлары җитәкчеләре коллективлары катнашында җыелыш узды. Барлыгы спорт бинaларында 400 кеше эшли. Ел эшчәнлегенә йомгак ясау, киләчәк паннары 2015 нче елга киңәшләшү – әлеге очрашуның төп темалары.

**«Буревестник»: 100-процентлы нәтиҗә!**

«Буревестник» 2014 ел нәтиҗәләре буенча беренче спорт бинасы иде. Уку-спорт комплексы директоры Марат Салихов коллектив эшчәнлегенә нәтиҗә ясады. Студентларның спорт белән күнекмәләр алуы, уку дәресләре күпфункциональ уен һәм тренажер залларда, йөзү бассейны һәм стадионда бара. Моннан тыш, уку өчен 2 лекцион аудитория, 3 кафедра билгеләнгән. Ә студентлар волейбол командасы «Академия-Казан» өчен тренерлык үзәге, медицина үзәге булдырылган. Студент-йөзүчеләр – ТР җыелма команда вәкилләре белән белән югары категорияле тренер Максим Дедловский эшли.

Һәр елны спорткомплекста 2 мең кеше йөри. Әлеге эшчәнлектә йөзү бассейны, футбол кыры, тренажер, кардио, уен һәм бию заллары бар.

Муниципаль программа «Пятилетка здоровья» буенча бушлай 1200 кеше шөгыльләнә. Алар арасында социаль-хокуклары якланмаган гражданнар, инвалид һәм пенсионерлар бар.

Объект нигезендә Октябрьск, Киров, Оренбург, Барнау, Ижевск, Мәскәү, Санкт–Петербург, Красноярск һәм Новосибирсктан җыелма командалар күнекмәләр ала. 200 бала (800гә кадәр) «Буревестник»та йөзү, синхрон һәм су асты йөзүе белән шөгыльләнә.

Ректор Йосып Якубов коллективның яхшы эшчәнлеген югары бәяләде һәм уңышлар теләде.

**Казан теннис академиясе: ITF бәясе бүләкләү**

Әлеге спорт бинасының нәтиҗәләре белән Казан теннис академиясе директоры Равил Ногуманов һәм төп инженер Игорь Савин таныштырды.

2014 нче елда 24 Бөтенрәсәй һәм Халыкара турнирлар, шул исәптән 10 000 доллар фонд белән CHALLENGER серия турниры (приз фонды $ 75 000), шулай ук Россия чемпионаты белән халыкара «Ельцин Кубогы» ярышлары уздырыла.

Приоритет юнәлеш булып теннис программасы үсешендә балалар теннисы тора, ул 9-18 яшькә кадәрге балалар өчен уздырыла. Өч ел спорт объектында уңышлы гына «TENNISLANDта җәй маҗаралары» ярышлары үтә.

2014 нче елда Казан теннис академиясендә ике зур вакыйга: Бөтендөнья робототехник олимпиадасы (WRO), 8-20 яшьлек 42 регионнан фехтование буенча 800 көчле спортсмен 101 илдән катнашты. Ярышларның тантаналы чарасында Россиянең спорт министры Виталий Мутко, Татарстан Республикасы президенты Рөстәм Минниханов һәм фехтование буенча Халыкара федерация президенты Алишер Усманов катнаша.

2014 ел нәтиҗәләре буенча, Казан теннис академиясе коллективы Халыкара теннис федерациясе (ITF)тан махсус бүләк алды, Дэвис Кубогы этабын, 2014 ел фехтование буенча дөнья чемпионатын узды.

Вузның уку-спорт комплексы базасында Татарстан Республикасы «теннис» буенча 350 бала теннис, 200 – бадминтон белән шөгыльләнә.

Гомумән алганда, ел Казан теннис академиясе өчен уңышлы үтте. Коллектив хезмәткәрләре ректордан нәтиҗәле эшләре өчен рәхмәт хатлары алды. 2015 нче елда Казан теннис академиясендә 50 чара уздырылган.

**Боз Сарае «Зилант»: бәхет безнең кулларда!**

Коллективның нәтиҗә җыелышы төп инженер Юрий Назаров тарафыннан хәбәр ителде. Узган елны объект техник сораулар, ремонт эшчәнлеге турында эш алып барган иде. УСК «Зилант» директоры Анатолий Зиндеев билгеләвенчә, «компрессор һәм вентиляцион җиһазлар – безнең бинаның йөрәге».

Анатолий Зиндеев билгеләвенчә, «Зилант»та якынча 75 мең кеше булган. Зур популырлыкны тимераякны прокатка алу, ярышлар үтү казанган.

Муниципаль спортмәктәбендә фигуралы шуу белән 53 бала (5 төркем), 314 бала (25 төркем) һәм 50 студент хоккейда уйный. «Зилант» хоккей студентлар командасы «Академия-Казан» 2014 елда Бөтенрәсәй кышкы универсиадада «көмеш» яулады.

«Зилант» хоккей турниры республика һәм Бөтенрәсәй масштабын кабул итә - сайлап алу этабы «Төнге Хоккей Лигасы», шәһәр беренчелеге, республика һәм ПФО. Беренчеләрдән 2014 нче елда CIHA (Canadian International Hockey Academy) «Зилант» базасында Канада хоккей мәктәбе Аллена Раймонд җыелмасы уздыра, хоккей клубы «йолдызы» «Ак Барс», академия студенты Денис Голубев вин чун Федерациясе белән берлектә вин чун буенча семинар уздыра. Язын 2015 нче елда «Торнадо» хоккей клубы мастер-класслар уздыра. УСК ЛД «Зилант» хореографик зал да буш тормый. Монда исә эшчәнлекне LEGACY проект педагоглары алып бара. Алар әлеге проект нигезендә балалар һәм яшүсмерләрдә креатив аң, эстетик зәвык тәрбияли...

**Татар-Ислам** **http://www.tatar-islam.com/publ/m_kal_l_r/analitika/3-1-0-12616**

**Универсиада бөек вакыйга булыр дип көтелә**

2013 елда Казанда үтәчәк Универсиадага һәр кызыксынган кеше үзенчә әзерләнәдер. Бу вакыйганы Казанның меңъеллыгын билгеләп үтү белән чагыштырырга булыр иде. Һәм ул, үз чиратында, бик күп туристларны җәлеп итәр, дип көтелә. Шәһәребезнең күпләрне кабул итә алачагы да мәгълүм.

**Универсиада — бөек спорт вакыйгасы**

Универсиада 1923 елдан бирле үткәрелеп килә. Үзенең мөһимлеге белән ул Олимпия уеннарыннан соң беренчелекне били. Чөнки анда Олимпия уеннарында кебек иң әһәмиятле 13 уен булачак. Әмма Олимпия уеннарының Универсиададан бер аермасы — анда 17дән 28 яшькә хәтле

студентлар катнаша. Универсиада елына ике тапкыр үткәрелә. Һәм җәйге һәм кышкы төрләргә бүлеп йөртелә.

**Универсиадага әзерлек башлануның тарихы**

Студентларның Халыкара җәйге уеннарын оештыру идеясе 2004/05 елларда барлыкка килде. Беренче тапкыр аны ул чакта республика яшьләренең спорт һәм туризм эшләре министрлыгын җитәкләүче, Рәсәйдәге Олимпия комитетының башкарма директоры Марат Бариев игълан итте.

2006 елның 30 июлендә 2013 елны җәйге Универсиада үткәрелү өчен гариза язылды. 2008 елда Казан икенче тапкыр Халыкара студентлар федерациясенең башкарма комитетына кабат гариза язды. Гариза кабул итүне хәзерге президент Р. Миңнеханов җитәкләгән иде. Шул ук елның май уртасында Халыкара студентлар федерациясенең баш комитеты делегатлары Рәсәйгә килә. Аларны Д. Медведев каршылый. 16 май көнендә делегатлар Казанда була, җөмһүриятебез белән таныша. Һәм: «Рәсәй президенты, Татарстан җитәкчеләре 2013 елда Казанда Универсиада үтүне хуплавы бик мөһим күренеш. Сезнең шәһәрегездән бары уңай тәэсирләр генә калды», — дип билгеләп үтә баш комитетның вице-президенты Стефан Берг. 9 май Җиңү көнендә Казанда марафон узган була. 4000 чакрымга сузылган арада Татарстан спортчылары 22 шәһәр аша факел алып бара. Алар Россия һәм Европа халыкларыннан Казанның конкурста катнашуын хуплый торган имзалар җыя. Эстафета 29 майда Брюссельдә тәмамлана.

**Казан һәм гомумән Рәсәй өчен Универсиада нинди әһәмияткә ия соң?**

1995 елдан башлап, Рәсәй спортчылары күп санлы медальләргә ия булды. Бу вакыт аралыгында 600ләп медаль яуланган. Әлбәттә, моны Универсиада өчен рекорд дип булмый. Шулай да бик яхшы күрсәткеч икәнлеге аңлашыла. 2007 елны Универсиада вакытында Таиланд, Банкогк башкалаларында 16 татарстанлының катнашып, бер көмеш, бер бронза

медаль яулаган иделәр.

**Универсиада өчен районнар сайлау**

Универсиадага әзерлекнең иң мөһим өлеше ул — спорт объектларына яраклы урын сайлау. Казанда 64 спорт объекты төзелүе исәпкә алынган иде. Моның өчен бюджеттан 604 миллион евро акча бүлеп бирелгән. Нигездә спорт объектлары Казанның 5 районында нигезләнәчәк. Җиңү проспекты, Оренбург тракты, Яңа Савиново районы, Казан үзәге, Елга аръягы районы. Спорт объектларының күпчелеге шәһәр үзәгендә булачак. Шәһәрнең бу районнырында яңа юллар төзеләчәк. Иң яхшысы метроның зур киңлекләр алуы. Универсиада өчен төзелгән бар объектлар да соңрак шәһәр югары уку йортларына тапшырылачак.

**Универсиада Авылында ниләр булачак?**

Универсиада Авылының гомуми мәйданы 43600 кв.м. Монда мәгълүмат үзәге, күңел ачу комплексы, дин бүлмәсе, спортсменнарның туклану урыны, матбугат үзәге һәм концерт залы урын алачак. Универсиада Авылы янәшәсендә тантана мәйданы, флаглар аллеясы һәм куркынычсызлык штабы урнашачак. Бирегә барлыгы 13500 кеше сыя. Студентларны урнаштыру шәһәр югары уку йортлары үтенече белән бара. 2010 елның 1 ноябренә Универсиада Авылына 36 илдән килгән 25833 студент яши.

**2013 елда узакчак Универсиаданың туристлык аспекты**

Һичшиксез, 2013 елда шәһәргә бик күп туристлар агылачак. Ә Казан бу кадәр халыкны кабул итәргә әзерме? Әлбәттә. Инде күп санлы кунакханәләр төзелгән. Һәм уңайлы шартлар да тудырылган. Хакимиятебез туристларны урнаштыруны үз өстенә ала. Барлык ярымишелгән биналар 2013 елга сүтелеп бетмәсә дә, алар туристларга искелекне күрсәтмәс. Шуны да билгеләп үтәсе килә: туристларны иң беренче каршы алып, кабул итү вазифасын «Казан» аэропорты башкарачак. Инвесторлар аны

төзекләндерү өчен 400 млн. доллор бүлеп биргән. Шуннан аэропорт 2000 туристтан да күбрәк кешене кабул итә алачак һәм танымаслык дәрәҗәдә уңай якка үзгәрешләр кичерәчәк.

**2013 елны Казанда үтәчәк Универсиаданың билгесе**

Аның рәсми символы — «Юни», ягъни республика гербында урнашкан Барсның энекәше. Аны символ итеп быел сайладылар.